РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ** ВАРЯШ-БАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**СОВЕТЫ**

*423979, РТ,Муслюмовский район, с.Варяш-Баш, ул.Кооперативная, 31а,*
Vbash.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-07-20*

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ XLIX УТЫРЫШЫ

**К А Р А Р № 3**

Вәрәшбаш авылы 25 октябрь 2019 ел

**Вәрәшбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 нче ноябрендәге 1 нче номерлы «Җир салымы турында» Карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Мөслим районы прокуратурасының 29.01.2019 ел, № 02-08-02-2019 күрсәтмәсен карау нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Советының 2018 елнын 28 нче ноябрендәге 1 нче номерлы «Җир салымы турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле өлеш өстәргә:

«3. Салым ташламаларын бирергә:

3.1. шәхси торак йортлар, шәхси ярдәмче хуҗалык, дачалар, бакча йортлары, гаражлар һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә (өлешләргә) карата җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә – физик затларга;

3.1.1. Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм Бөек Ватан сугышы инвалидларына;

3.1.2. Әфганстан республикасында интернациональ бурычларын үтәгән гражданнарга;

Әлеге карарның 3.1.1 – 3.1.2. пунктчаларында санап үтелгән салым түләүчеләр категориясенә керүче физик затларга ташлама 5000 кв. метр мәйданнан артмаган күләмдә салым салынмый торган җир кишәрлеге (өлеше) рәвешендә бирелә.

Әлеге карарның 3.1.1 – 3.1.2 пунктчаларында санап үтелгән салым түләүчеләр категориясенә керүче физик затларга һәм Вәрәшбаш авыл җирлеге территориясендә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган

кешеләргә салым ташламасы салым түләүченең теләге буенча бары тик бер җир участогы (өлеш) өчен генә бирелә.

Торак фонды биләгән җир кишәрлегенә (өлешенә) карата салым ташламасы анда салым түләүченең законнарда билгеләнгән тәртиптә даими теркәлүе (прпискасы) булган торак фонды объекты урнашкан җир кишәрлеге (өлеш) өчен бирелә.

3.2. салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә 100% күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

3.2.1. оешмаларга – җирләү өчен бирелгән кишәрлекләргә карата.

3.2.2. сәнәгать билгеләнешендәге җир кишәрлекләрендә инвестицион бизнес-проектларны тормышка ашыручы инвесторларга».

б) 3,4,5,6,7 өлешләрен 4,5, 6, 7, 8 өлешләре дип санарга.

2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң бер ай үткәч үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Авыл җирлеге Башлыгы** **З.М.Маннапова**